**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Туктар-Урдаласы авыл җирлеге**
**Туктар-Урдаласы авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 20 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Туктар-Урдаласы авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Туктар-Урдаласы авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, түбәндәге категория гражданнар: ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:

- Совет, Октябрь, Вахитов, Куйбышев урамнарындагы су линияләрен өлешчә алыштыру;

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Туктар-Урдаласы торак пунктындагы юлларны кардан чистарту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

.

.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туктар-Урдаласы авыл җирлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова